**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2022-2023 учебный год**
**6 КЛАСС**

**Критерии оценивания**

**Таблица ответов**

| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | | | | X | | | | | | X | X |
| **2** | X | X | | | | | X | | | | |
| **3** | | | X | | | X | | X | X | | |
| **4** | | | | | *X* | | | | | | |
| | ***задания по 4 балла*** | | | | | | | | | | |

1. Нечкә сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез. (4 балл)
1) Аз булсын, яхшы булсын.
**2) Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк.**
3) Эш беткәч, уйнарга ярый.
4) Ашыккан бер эшне ике эшләр.

2. Кайсы сүздә басым дөрес куелмаган? (4 балл)
1) әммá
**2) мәгълүмáт**
3) кагыйдә́
4) туганнардá

3. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да нокталар урынына ә хәрефе (4 балл)языла?
1) бел...н, х...зер, таб...н
2) мәк...лә, мәгъриф...т, м...сьәлә
**3) күм...ч, чир...м, үл...н**
4) сир...к, ...ш, тир...н

4. Ямьле, комлык, эшлә, озынча сүзләре нинди ысул белән ясалганнар? (4 балл)
**1) Сүз ясагыч кушымча өстәү юлы белән**
2) Сүзләрне кушу юлы белән
3) Сүләрне кыскарту юлы белән
4) Сүзгә яңа мәгънә өстәү юлы белән

5. Ярый сүзе нинди сүз төркеменә карый? (4 балл)
1) ымлык
2) фигыль
3) сан
**4) хәбәрлек сүз**

6. Яр астында тал яфракларында **көмештәй** саф иртәнге чык тамчылары ялтырый (Г. Гобәй) җөмләсендә билгеләнгән сүз кайсы җөмлә кисәге? (4 балл)
1) аергыч
2) хәбәр
**3) хәл**
4) тәмамлык

7. Кайсы рәттә җөмләнең тиңдәш кисәкләрен аера торган өтерләр бар? (4 балл)
1) Марат, кил әле яныма.
**2) Әдәбият дәресләрендә без әсәрләр укыйбыз, шигырьләр сөйлибез, бөек авторларның биографияләрен өйрәнәбез**
3) Без, алтынчы сыйныф укучылары, бүген әдәбият дәресендә булдык.
4) Мин, әлбәттә, яхшы укырга телим.

8. Авырта сүзенең синонимын табыгыз. (4 балл)
1) дәвалый
2) кайный
**3) сызлый**
4) түли

9. «Фольклор» сүзе нәрсәне белдерә? (4 балл)
1) халык акылын
2) халык сүзен
**3) “Авыздан – авызга” дигән мәгънәне**
4) хикмәтне

10. Кайсы әдип XIX йөзнең беренче яртысында туып, иҗат иткән? (4 балл)
**1) Каюм Насыйри**
2) Дәрдемәнд
3) Фәнис Яруллин
4) Муса Җәлил

11. Драмада сөйләшү(4 балл)
**1) диалог була**
2) монолог була
3) ремарка була
4) дөрес җавап юк

12. Әсәрләрнең авторларын языгыз. (8 балл)
“Беренче театр” Галиасгәр Камал
“Алмачуар” Галимҗан Ибраһимов
“Исемдә калганнар” Габдулла Тукай
“Әбүгалисина” Каюм Насыйри

13. Әсәрләрнең жанрларын языгыз. (8 балл)
“Беренче театр” комедия
“Алмачуар” хикәя
“Исемдә калганнар” автобиографик повесть
“Әбүгалисина” повесть

14. Бирелгән өзекне дәвам итегез, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)
“Барыгыз болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!
Елмайсын күреп шат аналар,
Юансын боеккан күңлегез.”
Муса Җәлилнең “Чәчәкләр” шигыре.

15. Бу өзек кайсы әсәрдән алынган? Аның исемен, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)
“Иртәгә сабан туе дигән кичне кем генә тыныч йоклый алды икән! Таңнан торып, күрше-күләнгә кереп-чыгып йөри торгач кояш чыга. Капка төпләре тулы бала-чага. Тагын бераздан урамнар атларының ял-койрыкларына кызыл чуклар таккан егетләр, үсмер малайлар белән тула. Шул арада, гармун тартып, җырлап та җибәргәлиләр.”
Гомәр Бәшировның “Туган ягым-яшел бишек” автобиографик повесте.

16. 15 биремдә бирелгән әсәрнең төп фикерен языгыз. Әсәрдә нинди тема яктырыла? (10 балл)
Гомәр Бәшировның “Туган ягым-яшел бишек” автобиографик повестенда халык рухының иң матур образлары, тормыш, яшәү төшенчәләренең иң тулы чагылышы гаүдәленде.

17. “Минем яраткан татар әдәбияты китабым” дигән тема буенча 5 җөмләдән ким булмаган инша языгыз. (20 балл)